# КАРАР

**23 ноябрь, 2023 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Ташлы Елга авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 23 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Кәркәүч авыл җирлеге Ташлы Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, экскаватор белән траншея эшләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре;
- юлларны кардан чистарту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре;
- урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре;
- җәен юлларны карап тоту, җәен территорияне чабу, табигый туфракта куаклар һәм вак урманлыкларны төпләү проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре;
- Ташлы Елга авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау буенча башка эш төрләре;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, - янгын гидранты һәм тирәннән суыртү насосы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре;
- яр буе зоналарын карап тоту һәм чистарту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, башка эш төрләре;
- зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 220 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 113 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 113 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы Елга авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Кәркәүч авыл җирлеге Ташлы Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, экскаватор белән траншея эшләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре;
- юлларны кардан чистарту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре;
- урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре;
- җәен юлларны карап тоту, җәен территорияне чабу, табигый туфракта куаклар һәм вак урманлыкларны төпләү проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре;
- Ташлы Елга авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау буенча башка эш төрләре;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, - янгын гидранты һәм тирәннән суырту насосы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре;
- яр буе зоналарын карап тоту һәм чистарту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, башка эш төрләре;
- зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Кәркәүч
авыл җирлеге башлыгы М.Ф. Зәйнетдинов